**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

**ТАТАРСТАНРЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.06.2020 № 288

**Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «Тәтеш муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы 2018 елның 31 августындагы 408 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2020 елның 21 маендагы 413 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «Тәтеш муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы 2018 елның 31 августындагы 408 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

VII бүлегендә:

1 пунктның бишенче абзацында «сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«7. Тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) аерым категорияләре белән эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр мәгариф хезмәткәрләренә аерым белем бирү оешмаларында бирелә.»;

7.1 пунктында:

беренче абзацта «сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

унберенче абзацта «сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

7.2 пунктның беренче абзацында «сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

15 нче таблицаның атамасында «сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

Әлеге карарның 1 нче кушымтасының «Россия Федерациясенең, ведомство (тармак), Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалары берлеге, Россия федератив Социалистик Республикасы бүләкләре өчен бирелә торган стимуллаштыручы түләүләр» турындагы бүлегенең 2 пунктын 2.6 пунктчасы белән тулыландырырга:

| | |
|---|---|
| «2.6. | «Мәгариф отличнигы» билгесе»; |

Күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларындагы хезмәткәрләргә түләүләр шартлары турындагы нигезләмәдәге III бүлекнең 2 пунктында «беренче-икенче төркем белән» сүзләрен «бер-ике төркем белән» сүзләренә алмаштырырга»;

V бүлегендәге 6 пунктка түбәндәге эчтәлекле уникенче абзац өстәргә::

2020 елның 1 гыйнварына кадәр ике айдан өч яшькә кадәрге балалар өчен ике яшь төркемнәрендә, өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балалар өчен өч яшь төркемендә хезмәт күрсәткән педагогик хезмәткәрләрнең һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри

квалификация төркемнәрендә эшләүчеләргә хезмәт интенсивлыгы өчен түләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәтнең авырлыгын исәпкә алып муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында»гы 2019 елның, 2 июлендәге 546 номерлы карары үз көченә кергән датага кадәр башкарыла.»;

«Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалары берлеге, Россия федератив Социалистик Республикасы ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегенең 2 пунктына күрсәтелгән нигезләмәгә 1 нче кушымталарны түбәндәге эчтәлекле 2.6 пунктчасы белән тулыландырырга:

| | |
|---|---|
| «2.6. | «Мәгариф отличнигы» билгесе»; |

Күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларының өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә түләү шартлары турындагы нигезләмә кушымтасының «Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалары берлеге, Россия федератив Социалистик Республикасы ведомство (тармак) бүләкләре» турындагы 1 нче таблицасын 2.7 пунктчасы белән тулыландырырга:

| | |
|---|---|
| «2.7. | «Мәгариф отличнигы» билгесе»; |

күрсәтелгән карар нигезендә расланган Татарстан Республикасы дәүләт һәнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә түләү хакындагы положениенең 2 пунктының 5 абзацындагы «300» санын «350» санына алыштырырга;

күрсәтелгән карарның 2 нче кушымтасының 1 нче таблицасының «Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалары берлеге, Россия федератив Социалистик Республикасы ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегенең 2 пунктын түбәндәге эчтәлекле 2.6 пунктчасы белән тулыландырырга:

| | |
|---|---|
| «2.6. | «Мәгариф отличнигы» билгесе»; |

Күрсәтелгән карар белән расланган югары белем бирү программаларын - бакалавриат, специалитет программалары, магистратура программалары гамәлгә ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең «Россия Федерациясе, Совет Социалистик Республикалары берлеге, Россия федератив Социалистик Республикасы ведомство бүләкләре» бүлеген түбәндәге эчтәлекле пунктчалар белән тулыландырырга:

| | |
|---|---|
| «1.14. | Россия Федерациясе мәгариф өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |
| 1.15. | Россия Федерациясе балалар һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсенең мактаулы хезмәткәре» |

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Тәтеш муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **А.Б. Семенычев**